# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр "Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2008 елның 22 декабрендәге 262-ФЗ номерлы Федераль закондагы (алга таба – Федераль закон) мәгънәдә кулланыла.

2 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу өлкәсе**

1. Әлеге Закон Федераль закон һәм "Татарстан Республикасы Конституция суды турында" 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) белән җайга салынмаган өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды (алга таба – Конституция суды) эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү үзенчәлекләрен билгели.
2. Әлеге Законның гамәлдә булуы мәгълүматтан файдаланучыларга Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

3 статья. **Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе

Конституциясе, федераль конституциячел законнар, Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Законы, шулай ук әлеге Закон һәм Конституция суды Регламенты белән гамәлгә ашырыла.

4 статья. **Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануның төп принциплары һәм алымнары**

Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануның төп принциплары һәм алымнары Федераль законның 4 һәм 6 статьялары нигезендә билгеләнә.

5 статья. **Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү рәвеше һәм теле**

1. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат телдән һәм документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә дә, бирелергә мөмкин.

2. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат, әгәр мондый мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыга дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, башка органнарга, оешмаларга һәм учреждениеләргә тәкъдим итү өчен кирәк булса, язма рәвештә бирелә.

3. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат, әгәр гарызнамәдә суд эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең башка алымы билгеләнмәгән булса, мәгълүматтан файдаланучының язма гарызнамәсенә җавап итеп язма рәвештә бирелә.

4. Күрсәтелгән мәгълүматны соратыла торган рәвештә бирү мөмкинлеге булмаганда, мәгълүмат булган рәвешчә бирелә. Мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматны соратыла торган рәвештә бирү мөмкинлегенең булмавы турында мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан күрсәтелгән рәвештә бирә алмауның сәбәбен күрсәтеп хәбәр ителергә тиеш.

5. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат гражданнарга, шул исәптән оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләренә, кабул итү вакытында телдән бирелә. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук телефон аша да тапшырыла.

6. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре аша тапшырылырга мөмкин.

7. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелә.

6 статья. **Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыларның хокуклары**

Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучы Федераль законның 8 статьясында билгеләнгән хокукларга ия була.

2 бүлек. **Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру, әлеге мәгълүматтан файдалануны тәэмин иткәндә төп таләпләр һәм мәгълүматны бирү тәртибе**

7 статья. **Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру**

1. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану аның вәкаләтле структур бүлекчәсе яисә вазыйфаи заты тарафыннан тәэмин ителә.

2. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат биргән өчен җаваплылар Конституция суды Рәисе тарафыннан билгеләнеп куела.

3. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат суд регламентында каралган тәртиптә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләрен исәпкә алып, гомуми файдаланудагы мәгълүмат системаларында, шул исәптән Интернет челтәрендә, шулай ук суд бинасында урнаштырыла.

4. Конституция суды эшчәнлеге турында телдән мәгълүмат, шулай ук электрон документ рәвешендәге мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыларга түләүсез бирелә.

5. Конституция суды эшчәнлеге турында язма мәгълүмат, әгәр Россия Федерациясе законнарында яисә Татарстан Республикасы законнарында башкача билгеләнмәгән булса, мәгълүматтан файдаланучыларга түләүсез бирелә.

8 статья. **Конституция суды эшчәнлеге турында Интернет челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалануны оештыру**

1. Конституция суды үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен Интернет челтәреннән файдалана, анда, гарызнамәне җибәреп була торган электрон почта адресын күрсәтеп, рәсми сайт ача.

2. Конституция судының рәсми сайтын булдыру, анда суд эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе, күрсәтелгән мәгълүматны яңарту сроклары, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләрен исәпкә алып, Конституция суды Регламентына тиешле нигезләмәләр кертү йә Конституция судының рәсми сайты турында аерым нигезләмә әзерләү юлы белән судның үзе тарафыннан билгеләнә.

3. Конституция судының рәсми сайтында мәгълүмат, шул исәптән Конституция судының йомгаклау карарлары, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

4. Рәсми сайттан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр, Конституция суды эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан чыгып, Конституция суды вәкаләтләре чикләрендә билгеләнә.

**9 статья. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү**

1. Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, әлеге статья нигезләмәләрен исәпкә алып, Федераль законның 3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Закон нигезендә бастырып чыгарылырга тиешле суд актлары текстлары, шулай ук Конституция суды чыгарган башка суд актлары текстлары, Федераль законның 15 статьясындагы дүртенче өлешендә күрсәтелгән суд актлары текстларыннан тыш, Интернет челтәрендә тулы күләмдә урнаштырыла.

3. Мәгълүматтан файдаланучыларны Конституция суды эшчәнлеге турында архив фондларындагы мәгълүмат белән таныштыру архив эше турында Россия Федерациясе законнарында һәм шулар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә, шулай ук архив эше турында Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының шулар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Мәгълүматтан файдаланучы Федераль законның 18 статьясында билгеләнгән тәртиптә бирелгән гарызнамә белән Конституция судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

**10 статья. Конституция суды бинасына (урынына) керү**

Татарстан Республикасы Конституция суды бинасына (урынына) иркле кереп йөрү тәэмин ителә.

**3 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре**

**11 статья. Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 3 июле
№ 50-ТРЗ